ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 142 от «18» 05 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган «НОКРАТ» пляж комплексы хезмәтләренә һәм мунча хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшен оештыру принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 17 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елны 08 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль предприятие һәм учреждениеләре тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләргә һәм эшенә тарифларны билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында», 5-6 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган «НОКРАТ» пляж комплексы хезмәтләренә һәм мунча хезмәтләренә тарифларны кушымта нигезендә билгеләргә;

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 12 гыйнварындагы 12 нче карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов

0000011410

Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
18.05 2022 ел, № 142 нче
карарына 1 нче кушымта

«НОКРАТ» пляж комплексы хезмәтләренә һәм мунча хезмәтләренә тарифлар

| Күрсәтелүче хезмәтнең исеме | Халык категориясе | 1 кешегә хезмәттән файдалану дәвамлылыгы | Тариф күләме, сумнарда |
|---|---|---|---|
| Мунчада юыну | 14 яшьтән алып пенсия яшенә кадәрге категория | 1 сәгать | 120 |
| | 7 яшьтән алып 14 яшкәчә булган балалар | 1 сәгать | 100 |
| | Барлык категория пенсионерлар | 1 сәгать | 100 |
| | 7 яшькә кадәрге балалар | 1 сәгать | түләүсез |
| | Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар | 1 сәгать | түләүсез |
| «НОКРАТ» пляж комплексы хезмәтләре | Өлкәннәр һәм 14 яшьтән алып балалар | 2 сәгать | 400 |
| | 7 яшьтән алып 14 яшкәчә булган балалар | 2 сәгать | 200 |
| | 7 яшькә кадәрге балалар | 2 сәгать | түләүсез |
| | Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар | 2 сәгать | түләүсез |